ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«22» декабрь 2020 ел **№ 1052**

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 20 ноябрендәге 907 номерлы «Арча муниципаль районы коммуналь комплексы оешмаларының 2021 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Арча муниципаль районы коммуналь комплексы оешмаларының 2021 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында» 2020 елның 20 ноябрендәге 907 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә;

-3 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Фазыловка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Мөхәррәмов

*Арча муниципаль районы*
*башкарма комитетының*
*22.12. 2020 ел, №1052*
*карарына 2 нче кушымта*

**Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга торак урыныннан файдаланган өчен (наемга алган өчен)**
**БАЗА СТАВКАСЫ**

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге | 2021 елга хезмәт күрсәтү өчен үлчәү берәмлегенең база ставкасы (сум) |
|---|---|---|
| Наем буенча база ставкасы | Аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м. | Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 1140 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре һәм социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннардан файдаланучылар өчен түләү(наем өчен түләү) күләмен исәпләү методикасы нигезендә. |